КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 февраль г.Казань № 104

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасы»н) раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән расланган «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасы»н) раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 20 гыйнвар, 14 нче, 2020 ел, 25 сентябрь, 867 нче, 2020 ел, 01 декабрь, 1081 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен

Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлектә:

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.10 һәм 2.11 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «2.10. | Тикшерүдә тоту-күзәтчелек чаралары уздырганда юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата куела торган мәҗбүри таләпләрнең Җыелма исемлеген актуальләштерү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүдә тоту-күзәтчелек чаралары уздырганда куела торган мәҗбүри таләпләрнең җыелма исемлеге | квартал саен | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнары»; |
| 2.11. | «Тикшерелгән бизнес» (provbiz.ru) интернет-ресурсында тиешле дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга кагылышлы материалларны урнаштыру | «Тикшерелгән бизнес» (provbiz.ru) интернет-ресурсында урнаштырылган материаллар тиешле дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга кагылышлы материаллар | ел дәвамында | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнары, тапшырылган вәкаләтләрне тикшереп торучы тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнары»; |

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.3 һәм 5.4 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «5.3. | «Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болытлы карар» (алга таба - ТКЭ ҮБК) дәүләт мәгълүмат системасына планлаштырыла торган һәм уздырыла торган контроль-күзәтчелек чаралары турында мәгълүмат кертү, контроль-күзәтчелек чаралары статусын үз вакытында үзгәртү | ТКЭ ҮБК планлаштырылган һәм уздырыла торган контроль-күзәтчелек чаралары турында мәгълүмат кертү - 100 процент, контроль-күзәтчелек чаралары статусын үз вакытында үзгәртү | ай саен | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнары»; |
| 5.4. | «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә | ТКЭ ҮБК «Идарә» ДАСта чагылдырылган белешмәләр булу (тикшерүдә тоту-күзәтчелек чарала- | хисап чорыннан соң килә торган айның 15 числосы (15 гыйнвар, | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ашыру турында белешмәләр» 1 нче контроль формасында чагылдырылган мәгълүматларга нигезләнеп, ТКЭ ҮБК (алга таба - «Идарә» ДАС) тәмамланган контроль-күзәтчелек чаралары буенча мәгълүмат кертү | рының төгәлләнгән саны буенча - 100 процент | 15 июль) | тикшерүдә тоту-күзәтчелек органнары»; |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин